**СОВЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢАЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 28 нче октябре

№ 2-7

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 27.03.2020 № 65-139 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 27.03.2020 № 65-139 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советында Муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 15.06.2020 № 67-144, 26.03.2021 № 9-26, 28.06.2021 № 14-40, 31.05.2022 № 22-72, 9.02.2023 № 31-103; 24.08.2023 № 38-118; 8.04.2024 № 44-138; 24.10.2024 № 48-147; 18.12.2024 №50-152 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 бүлегенең 3 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен.»;

1.2. Нигезләмәнең 6 бүлегенең 3 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Бу карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы Д.С. Гайнуллин